ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ НИЖНЕКУЮКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422741 Республика Татарстан Атнинский район село Нижний Куюк Тел. 3-32-47

# КАРАР

«04» апрель 2025 ел №102

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Көек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 8 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) адресы буенча, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча:

Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71а йорт (администрация бинасы);

Югары Көек авылы, Тукай урамы, 59а йорт (авыл клубы бинасы) халыкка җиткерергә.

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.

Совет Нижнекуюкского сельского поселения
Түбән Көек авыл җирлеге советы
ИНН 1610000518

Түбән Көек авыл җирлеге Советының
2025 елның 4 апрелендәге
102 нче номерлы карарына 1 нче кушымта


Түбән Көек авыл җирлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Атамыш авылы,** Гагарин урамы, №1,№2 йортлар<br>**Иске Шимбер авылы,** М.Җәлил урамы, №1 - №37 йортлар<br>**Яңа Шимбер авылы, Тукай урамы** №1 - №30йортлар | 64 |
| 2 | 2 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Яңа Шимбер авылы, Тукай урамы** №32 - №49 йортлар<br>**Түбән Көек авылы,** Татарстан урамы, № 1 - № 42 йортлар | 64 |
| 3 | 3 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Көек авылы,** Татарстан урамы, № 43 - № 92 йортлар | 64 |
| 4 | 4 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Көек авылы,** Татарстан урамы, № 93 - № 146 йортлар | 65 |
| 5 | 5 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Түбән Көек авылы,** Татарстан урамы, № 148 - № 158 йортлар<br>**Югары Көек авылы**, Тукай урамы, №101 - №148 йортлар | 54 |
| 6 | 6 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы | **Югары Көек авылы**, Тукай урамы, №49 - №100 йортлар | 54 |
| 7 | 7 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Югары Көек авылы**, Тукай урамы, №1 - №48 йортлар | 54 |


Түбән Көек авыл җирлеге Советының
2025 елның 4 апрелендәге
102 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**


Атамыш авылы





Иске Шимбер авылы




Яңа Шимбер авылы




Түбән Көек авылы




Югары Көек авылы

